СОВЕТ НИЖНЕСУНЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.К.Маркса, д.18а, с. Нижняя Сунь,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422158

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТҮБӘН СОН АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
К.Маркс ур., 18а нче йорт, Түбән Сон авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422158

тел.(факс): (85563) 3-01-41; e-mail: NSun.Mam@tatar.ru, www:mamadнsh.tatarstan.ru

Решение КАРАР

№ 1-26- 02.10.2017 ел..

# Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, "Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 маддәсе, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 маддәсе, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нчы елның 20 сентябрендә кабул ителгән 7 нче санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советының “Референдум уздыру инициативасы турында” 2017 нчы елның 02.10. кабул ителгән 1-26 нче санлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге Советының 02.04.2014 елның, 2-33 нче санлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлегендә гражданнардан үзара салым акчасын җыю һәм куллану турындагы Нигезләмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Сон авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм аларны куллану буенча җирле референдум үткәрүне 2017 нчы елның 19 нче ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Сон авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт

итүчеләрдән кала, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:
- Түбән Сон авылы, Колышчы авылында су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау ( материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен түләү).;

--Рәхмәт Аланы поселогында су башнясын челтәрләрен ремонтлау ( материал, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алыштыру, эшләр өчен түләү).;
-- Түбән Сон авылында Зәңгәр Күл урамында юлларга вак таш җәю (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);;
- Түбән Сон, Колышчы авылында пожар гидранты сатып алу урнаштыру.

« ӘЙЕ » « ЮК »

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә. Элеге карарны Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемә алам.

Башлык,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Сон авыл җирлеге Советы рәисе Гафиятуллин Р.Ш.